# Ышанам

*(«Сулыш» бәянына бәяләмә)*

Әлеге китап үзе колачлаган чорны дөрес сурәтләве белән көчле. Автор халык тормышын тулы канлы тасвирлый. Кыз белән егет, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне тар кысаларда гына сурәтләп калмый. Ул аларны халык язмышы, авыл язмышы, ил язмышы белән бәйли...

Авыл кешеләре яшәешен, аның бихисап мәшәкатьләрен, Туган як табигатен тасвирлаганда, чәчмә рәвештә язып, шигъри дәрәҗәгә күтәрелү бар Р. Аллабирде хикәяләрендә. Авыл тормышын, ишле гаиләләрен җигелеп тартучы Яудәт, теләсә нинди тимерне суккалап төзәтеп бирүче Мәҗит абыйлар, авылның маңгайдан тир агызучы тормышын ямьләп, такмаклар көйләүче Кызык Ишбулды. Ә МТСта эшләүче, тумыштан ишетмәгән, сөйләшмәгән, ләкин трактор моторына кулын куеп торса да, төзексезлек кайда икәнен әйтеп биргән Әсхәт! Яки менә фронтовик Фәткулла абзый. Ул авиация берләшмәсе ясый алмаган тешле тимерне ясый да бирә... Дөньяны әнә шулар тотып тора.

«Сулыш» бәяны авылны урталай ярып аккан инеш сыман. Ул авыл кешеләренең киң күңеллелеген, юмартлыгын, тырышлыгын үзенә сеңдереп ага да ага, үз дулкыннарында алар турында башкаларга да хәбәр итә.

Әсәрнең төп герое Рәкыйп гомере буе кояшка таба бара...

Бәян – мәхәббәт чәчәкләре чигелгән кулъяулык. Ул этиәнисенә, Туган җиренә, аның кешеләренә, табигатенә, мәктәбенә табына. Егетнең өй каршысындагы бакчасында җемелдәүче гөл булып Гөлчирәсе яши. Ул кыз шулай яшәргә лаек.

Рәкит Аллабирде төрле милләттән булган гади хезмәт кешеләрен якты җылылык белән сурәтли. Күр син аның ирле-хатынлы Кирәй бабай белән Җәннәт абыстаен, Бәхет җизнәсен! Алар – казах халкының горурлыгы бит. Тимерче Фәткулланы НКВД тырнагыннан коткарган рус офицеры,

Дамаск корычыннан коелган кылычны тырыш татар әсиренә бүләк иткән немец фермеры, армиядәге тугры дусты, Мәскәү егете Николай Морозов, Мораптал мәктәбе директоры башкорт Рәфыйк Шәрәфетдин улы Сыртланов, әрмән егете Сейран Арутюнян... Нәкъ менә шул ир узаманнарыннан үрнәк алып, безнең Рәкыйп: «Юк инде. Болай булгач, кыйналсам кыйналам, үлсәм үләм, әмма... татар булып калам барыбер. «Менә татар нинди икән!» дисеннәр», – ди. Бу – аның кыйбласы.

Уфа военкоматында кыйналу, Совет Армиясендә хезмәт иткәндәге кимсетелүләр, аннан кайткач күргән фаҗига дә Рәкыйпнең кыйбласын үзгәртми. Ул татар булып яши.

Варшава килешүе илләре корабларына хәрби өйрәнү өчен китерелгән меңләгән тонналы сугыш кораллары төялгән эшелонны шартлаудан коткарган өчен биреләсе «Адмирал Кузнецов» медале дә Рәкыйпкә 30 ел үткәч кенә тапшырыла...

Рейхстаг түбәсенә дөньяда беренче булып байрак кадаган Газетдин Заһитов искә төшә. Эшләгәндә, сугышканда, коткарганда – татар кирәк. Ашаганда, бүлешкәндә, бүләкләгәндә – юк...

Рәкит Аллабирденең «Сулыш» бәянын укыган якташларының күзләренә яшь тула. Чөнки әсәр мәңгелеккә күчкән йөзләгән кешеләрне дөньялыкка «кайтара», безнең белән янәшә атлата, аларга рәхмәт догасы укый. Без Гази Заһитовны, Гайшә апайны, Яүдәт, Фәткулла, Әсхәт абыйларны, Каркадил басуын, Сазанлы буйларын, авылны мең давылдан саклап имгәнгән, картаеп ауган теге алып тал тирәкне онытырга тиеш түгел.

Бу бәян – аларга изге һәйкәл...

Әсәрнең «Сулыш» дип исемләнүе дә уңышлы. Җандагы, тәндәге һәр күзәнәкне туендыручы Туган җир һавасы җитми авылыннан киткәннәргә. Чөнки адәм баласы – Туган җирнең бар байлыгы, хозурлыгы белән тудырылган иҗат җимеше ул.

Һәр заманның үз авырлыклары. Батыршага, Тукайга тормыш җиңел булганмы? Мөхәммәт Мәһдиев, Салих Сәйдәшев ни кичергәннәр дә, Фәнис Яруллин һәм Рәкит Әбделмәнов ничек яшәгән һәм яши?! Татарга җиңел булган чор тарихта юк һәм булмаячак. Без һәр кыенлыктан җиңүче булып чыгарга тиеш! Мин моңа ышанам. Безне Аллаһ ташламасын.

**Рафаил ГАЗИЗОВ,** *шагыйрь, прозаик. Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Һанс Кристиан Андерсен исемендәге әдәби бүләкләр иясе*

# Аһәң

*(Сүз башы)*

> ...Ялгыз агач. Кайда шаулап торган
> Күкрәп үскән горур тирәклек?
> Җайлап кына үтә, юмарт җирне
> Талый бара шәрә сирәклек...*
>
> *«Кош»*

*Көзнең соңгы гарасаты, бар гайрәтен җигеп, авыл тирәләрен айкады-айкады да урам башындагы йөзьяшәр тирәкне, төбе-тамыры белән кубарып, юл читенә алып ташлады. Бу тирәк, ябалдашларын киң җәеп, бер урамлы авылны яшел төскә манып, җәйге челләләрдә тирә-якны күләгәсе белән саклап, кайнар һаваны җиләтеп торса, кышкы зәмһәрир салкыннарга түзеп, әче җилләрне өй-каралтыларга үткәрми саклап-ышыклап торган агачсыз калгач, урам ялангачланды, авыл ятим калды, көз тагын да шыксыз тоелды...*

*Дөнья дәрьяларын гизгән, ниһаять, юл-тәкъдирләре туган якка кайтарган бәхет эзләүчеләрнең, авыл урамына кергәнче Зыялы чичән Аю бабай утырткан тирәк янында бераз хәл җыеп, өс-башларын рәтли-рәтли, очрашу мизгелләре алдыннан кичергән татлы сагыну хисләре, киткәннәрнең соңгы хушлашкандагы аерылышу сагышының аһәңе генә сыкрады...*

*Аяусыз эзәрлекләгән замана җилләреннән ышыклану эзләп, мәгърур Урал тау итәгендә ургып аккан әрсез Юшатыр елгасы буенда, күркәм-юмарт Сазанлы куенында яклау-иркәләү табып, Яңа Аллабирде авылына нигез салган татар мосафирларының арба тәгәрмәчләре шыгырдавыннан башланган борынгы аһәңдә халкымның моң-зары да, бәхет-кайгысы һәм кеше күңелен юаткан кошлар тавышла-*

---

* Р. Аллабирденең «Сулыш» бәянына эпиграфлар итеп алынган кайбер шигырьләре әлеге китапта урын алды.

*ры, курай моңы, гармуным чыңлавына кушылып, бердәнбер мәхәббәтем белән тәүге очрашуның кадерле мизгелләре чагыладыр кебек...*

*Кайчандыр тигез нигезләрне тутырып утырган өйләрне, бер-берсенә сыенган бакча-сарайларны уратып тезелгән горур тирәкләрнең аһәңе, ауган агачның ярдәм үтенгән кебек күккә таба тырпайган тамыр-бармакларын кочып-сыйпап үткәч, сирәкләнгән нигезләрне барлап, хушлаша-эзләнә урам өстендә бөтерелде-бөтерелде дә, бәхилләү табалмыйча, һавага таралып тоныкланды, сүнде...*

*Бу язмаларның дөнья күрүенә – тарих катламнарының тынычлыгын бозмый-кузгатмый гына, бары тик гаять дәрәҗәдә самими-ихлас, әмма кылган гамәлләрендә тәвәккәл, нинди генә авыр чорларда да киң күңеллелеген саклый алган кунакчыл, ихтыярлы, гадел авылдашларымны сагынып-барлап, яңа буын белән бергәләп ата-бабаларыбыз төбәген тагын бер кат (бәлки, соңгы тапкыр?..) әйләнеп килү ихтыяҗы әйдәгәндер...*

*Бәлки, шуңа да язмыш өермәсе, чалт аяз, кояшлы тормыш күгеннән кубарып алып, кырыс чынбарлыкның төпкеленә томырганда да, хыял атының ялына чат ябышып, һаман максатына – илаһи яктылыкка таба омтылган шушы авылның бер баласы аша бәян ителгән хатирә-истәлекләр, һичшиксез, туган ягыма кагылышлыдыр.*

*Омтылышым – төрле якларга сибелгән авылдашларымның хозурына ирешеп, аларның хәтер төпкелләрендә сакланган истәлекләрен яңартып, күңелләре туган якка, туган туфракка тартылып, уңдырышлы җирдә яңа үсентеләр баш төртеп, агачлар шаулавы, кошлар тавышы, балалар чыр-чуы белән тулган авазларга төренгән авылга хис-кичерешләремнең кайтавазы – аһәңебез кайтканын күрү теләгедер...*

*Ә инде нәрсәнедер дәлилләү-исбатлау яисә инкяр итүне мәңгелек хакыйкать – галиҗәнап ВАКЫТ агышына тапшырыйк.*

# Сулыш

(Бәян)

